СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 10 от 06.10.2020

на № _от ________

# К А Р А Р

Саба муниципаль районы Советының 2018 елның 31 августындагы 253 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу комиссиясе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының “Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында” 2018 елның 31 августындагы 253 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазифаи тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** түбәндәге эчтәлекле 3.24. пунктын өстәргә:

“3.24. 3.2.1., 3.2.3., 3.2.4 пунктында каралган мотивлаштырылган бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) сорату нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы “б” пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм “д” пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм белдерүләрне алдан карау йомгаклары буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3., 3.11.1. пунктлары нигезендә карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.”

**2.** Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов